МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2022 Казан ш № 896

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2019 №328, 14.11.2019 №1018, 31.03.2020 №216, 23.06.2020 №454, 08.10.2020 №713, 20.10.2021 №773 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 28 сентябрендәге 896 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1064 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Преамбулада «Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт эшчәнлек стандартын раслау турында» 2018 елның 3 августындагы 518н номерлы» сүзләрен «Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандартын раслау турында» 2022 елның 28 мартындагы 174н номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентында:

1 - 5 бүлекләрне киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасында инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең бердәм, тулы, сыйфатлы һәм тигез мөмкинлекле булуын тәэмин итү максатында эшләнде.

1.2. Регламентта инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча алар үз вәкаләтләрен (алга таба – вәкаләт) гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәкләре) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибен һәм гамәл кылу (административ процедуралары) эзлеклелеген билгеләнә.

1.3. Мөрәҗәгать итүчеләр булып, туры килә торган эш эзләү максатларында халыкның мәшгульлек үзәгендә исәптә тора торган, федераль медик-социаль экспертиза учреждениесе (алга таба – МСЭ учреждениесе) тарафыннан эшләнә торган инвалидны тернәкләндерү яисә абилитацияләү

буенча индивидуаль программада (алга таба – ИПРА) булган киңәшләрне исәпкә алып, эшкә урнашканда булышлык күрсәтүне оештыру рәвешендә индивидуаль ярдәм күрсәтелүгә мохтаҗ булган, шөгыле булмаган инвалидлар тора.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Инвалидларга эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча күрсәтелә. Халыкның мәшгульлек үзәкләренә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.

2.2.2. Озата йөрү рәвешендә мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль ярдәм итүне гамәлгә ашыра торган халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан шартнамә нигезендә җәлеп ителә торган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтүгә хокуклы булган дәүләткә карамаган оешмалар (алга таба – дәүләткә карамаган оешма), шул исәптән ихтыяри (волонтерлык) оешмалары тарафыннан озата йөрүне гамәлгә ашыру рөхсәт ителә

2.2.3. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – КФҮ) яисә КФҮ ерактагы эш урынына дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формада гариза (алга таба – гариза) биргәндә булышлык күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.2.4. КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләре:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәндә озата йөрүне

оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандартын раслау турында» 2022 елның 28 мартындагы 174н номерлы боерыгы белән расланган Инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек стандартына (алга таба – Стандарт) 2 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча рәсмиләштерелгән һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сертивикаты;

рәсмиләштерелгән һәм мөрәҗәгать итүче белән эш бирүчегә җибәрелгән, инвалидны эшкә урнаштыруны рәсмиләштергәндә, эш урынында һөнәри яраклаштырганда, аның эш урынына кадәр һәм киргә һәм эш бирүче территориясе буенча хәрәкәт итү юлын формалаштырганда инвалидны озата йөргәндә киңәш ителә торган чараларның индивидуаль планы (алга таба, тиешенчә – индивидуаль план, эш урынында мөрәҗәгать итүчене озата йөрү).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

Халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформасын (https://www.trudvsem.ru/) (алга таба – Бердәм цифрлы платформа), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталын (http://www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) кулланып, электрон документ формасында;

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән кәгазь чыганакта.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Гаризаны бирү ысулына карап (халыкның мәшгульлек үзәгендә яисә КФҮ һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урынында, Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша), дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган чоры гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны теркәгән көннән башлап 48 эш сәгатеннән артмаска тиеш, Сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрүне гамәлгә ашыру вакытыннан тыш.

2.4.2. Бирелгән Сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү чоры аны рәсмиләштергән көннән башлап алты ай тәшкил итә.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

2.5.1. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр:

Стандартка карата 1 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзе туры килә торган эш эзләү максатларында исәптә тора торган халыкның мәшгульлек үзәгенә Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша электрон документ формасында тапшырыла;

мөрәҗәгать итүче турында аның тарафыннан Бердәм цифрлы платформага, Татарстан Республикасы порталына кертелгән белешмәләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

Бердәм цифрлы платформадагы шәхси кабинет аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

КФҮ яки КФҮнең ерактагы эш урыны аша, халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгәндә, Бердәм цифрлы платформага керү мөмкинлеген тәэмин итеп.

Мөрәҗәгать итүче электрон формада гариза биргәндә булышлык күрсәтүне сорап, халыкның мәшгульлек үзәгенә яисә КФҮ, ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итә ала.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә Бердәм цифрлы платформага, Бердәм порталга, Татарстан Республикасы

порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән барган очракта, мөрәҗәгать итүче паспортын яисә аны алыштыра торган документны күрсәтә.

2.6.2. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар һәм белешмәләр:

мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турында белешмәләр (гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта), халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан «Федераль инвалидлар реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан соратып алына торган өземтә (алга таба – ФИР ФДМС);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек хезмәте органнары һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре арасында мәгълүмат алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан соратып алынган эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында МСЭ учреждениеләре киңәшләре.

2.6.3. Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле оешмалардан турыдан-туры алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.5. Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

2.8.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турында мәгълүматлар булмау;

МСЭ учреждениесеннән мөрәҗәгать итүченең эш белән тәэмин иткәндә озата йөрүгә ихтыяҗлы булмавы турында киңәш алыну;

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүченең эш белән тәэмин итүгә мохтаҗл булмавы турында карар кабул итү.

2.8.3. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән очракта, Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларының булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

халыкның мәшгульлек үзәге әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә;

мөрәҗәгать итүче гаризаны кире алган очракта;

мөрәҗәгать итүчене Сертификат озата йөрү гамәлдә булу вакыты бетүгә бәйле рәвештә тәмамланган очракта;

мөрәҗәгать итүче туры килә торган эш эзләү максатларында теркәү исәбеннән төшерелгәндә.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.10.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бердәм цифрлы платформаны кулланып, чират тәртибендә бирелә.

Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.10.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алу турындагы гариза буенча мәгълүмат бирүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты – 60 минут.

### 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителгән дип санала.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза ял көннәрендә яки эшләми торган бәйрәм көнендә җибәрелгән очракта, гаризаны җибәрү көне булып аннан соң килә торган көн санала.

2.11.2. Гаризаны кабул итү турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә гариза кабул ителгән көнне Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәкләре җибәрә торган белдерүләр Бердәм цифрлы платформа аша, автомат рәвештә формалаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә аңа белдерүләрне Бердәм цифрлы платформасы аша җибәрү турында хәбәр итү хәбәр текстларын автомат рәвештә формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүченең гаризада күрсәтелгән электрон почтасына җибәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

### 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска

ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

бүлмәләрнең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә халыкның мәшгульлек үзәкләренең дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләре тарафыннан ярдәм күрсәтү;

мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында Бердәм цифрлы платформада, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта, Бердәм цифрлы платформа, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге.

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара хезмәттәшлек итү саны (шәхсән килгән очракта):

гаризаны электрон формада биргәндә булышлык күрсәтү – бер тапкырдан артыграк түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

2.13.4. Мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара элемтәгә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.5. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.

2.13.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү (консультация бирүдән һәм гаризаны электрон формада бирүдән тыш) КФҮ, КФҮ ерактагы эш урынында гамәлгә ашырылмый.

2.13.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ, ерактагы эш урыннары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыннары белән төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыннарының мөрәҗәгать итүчеләр белән – КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыннарының эш регламенты белән.

2.13.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм цифрлы платформадагы шәхси кабинеты аша, Татарстан Республикасы порталында, КФҮ, КФҮнең ерактагы урынында алынырга мөмкин.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән яки халыкның мәшгульлек үзәге тәкъдиме белән халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итә ала.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм цифрлы платформада, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм цифрлы платформа, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Бердәм цифрлы платформа, Бердәм портал, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гариза Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелә ала.

2.14.4. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм цифрлы платформада гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Мөрәҗәгать итүчеләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итү өчен язу) Татарстан Республикасы порталы, халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы порталы яки халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш,

мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

Бердәм цифрлы платформа;

Физик затлар регистры.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

гаризаны кабул итә;

мөрәҗәгать итүче турында Бердәм цифрлы платформа булган белешмәләрне анализлау, эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәтү вакытында инвалидның озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында карар яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;

эшкә урнаштыру турында эш бирүче белән сөйләшүләр алып барганда мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча чаралар исемлеген билгеләү, мөрәҗәгать итүчене озата йөрү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенең җаваплы белгечен билгеләү яки Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтергә хокуклы булган, озата йөрү рәвешендә мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыра торган дәүләткә карамаган оешманы (алга таба – дәүләткә карамаган оешма) сайлау;

Сертификат формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү;

Сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү нәтиҗәләре турында Бердәм цифрлы платформага мәгълүмат кертү;

мөрәҗәгать итүчене эш урынында озата йөрү буенча тәкъдим ителгән чаралар исемлеген билгеләү, эш бирүче белән аның хакында фикер алышу;

индивидуаль планны формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүче белән эш бирүчегә җибәрү;

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хаталар) төзәтү.

### 3.2. Гражданинның гаризасын кабул итү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Бердәм цифрлы платформа аша гариза белән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү буенча гамәлләр.

Гариза һәм аңа беркетелгән документлар Бердәм цифрлы платформа аша халыкның мәшгульлек үзәгенә алына.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документларны кабул итү һәм Россия

Федерациясе законнарында, шул исәптән әлеге Регламентта билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча беренчел тикшерү уздыруның максималь чоры – бер эш көне.

Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып гаризаны кабул итү тора.

Нәтиҗә Бердәм цифрлы платформада электрон формада теркәлә.

### 3.3. Мөрәҗәгать итүче турында Бердәм цифрлы платформа булган белешмәләрне анализлау, эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәтү вакытында инвалидның озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында карар яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүчедән гариза кабул иткән көнне халыкның мәшгульлек үзәге, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып, ведомствоара гариза юллау юлы белән, ФИР ФДМС аша мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турындагы белешмәләрне сората.

Мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турында мәгълүматлар булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге ведомствоара гаризага җавап алынган көннән соң икенче эш көне узганчы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә карар кабул ителгән көннән соң икенче эш көненнән соңга калмыйча, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, белдерү җибәрә.

ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакыты мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап җиде эш көненнән артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турында белешмәләр алынган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, халыкның мәшгульлек үзәге әлеге белешмәләрне анализлый, Регламентның 3.3.2 һәм 3.3.3 пунктларында каралган очраклардан тыш, булышлык күрсәткәндә озата йөрүгә мохтаҗ булуы яки мохтаҗ булмавы турында карар кабул итә, тиешле белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертә.

3.3.2. Булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булмавы турында карар кабул ителгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге карар кабул ителгән көннән соң киләсе эш көне узганчы мөрәҗәгать итүчегә, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү җибәрә.

3.3.3. Мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турындагы белешмәләрне анализлау нәтиҗәләре буенча булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗлыгы турында МСЭ учреждениеләреннән киңәшләр алу таләп ителсә, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең инвалидлыгы турында белешмәләр алынган көннән соң киләсе эш көне узганчы МСЭ учреждениесенә тиешле гаризаны юллый.

МСЭ аша кирәкле белешмәләрне алу срогы гариза җибәрелгән көннән соң 10 эш көненнән артмаска тиеш.

3.3.4. МСЭ учреждениесеннән булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать

итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында киңәшләр алынган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге, МСЭ учреждениесеннән киңәшләр алынган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында карар кабул итә.

3.3.5. МСЭ учреждениесеннән эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булмавы турында киңәшләр яисә эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәткәндә инвалидның озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында киңәшләр бирү мөмкин булмаган бәяләмә алынган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге тиешле киңәшне (бәяләмәне) алган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге карар кабул ителгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрә.

3.3.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булмавын яки булуын максималь тикшерү вакыты – бер эш көне.

3.3.7. Халыкның мәшгульлек үзәге ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган белешмәләр һәм документлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген билгели. Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе – дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын яки булмавын билгеләү.

Процедураның максималь вакыты – 20 эш көне.

### 3.4. Эшкә урнаштыру турында эш бирүче белән сөйләшүләр алып барганда мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча чаралар исемлеген билгеләү, мөрәҗәгать итүчене озата йөрү өчен халыкның мәшгульлек үзәгеннән җаваплы белгечне билгеләү яисә дәүләткә карамаган оешманы сайлап алу.

3.4.1. Эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында карар кабул ителгән көннән соң киләсе эш көненнән соңга калмыйча, халыкның мәшгульлек үзәге Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә түбәндәгеләрне билгели:

эшкә урнаштыру турында эш бирүче белән сөйләшүләр уздырганда мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча чаралар планы, ул Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан эшләнгән Стандартны үтәү буенча технологик картада (алга таба – технологик карта) билгеләнә;

мөрәҗәгать итүчене озата йөрү өчен халыкның мәшгульлек үзәгеннән җаваплы белгечне билгели яисә дәүләткә карамаган оешманы сайлап ала.

3.4.2. Эшкә урнаштырганда эш бирүче белән сөйләшүләр уздырганда мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча җаваплы затны билгеләгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча җаваплы затны билгеләү турында боерык (алга таба – боерык) формалаштыра.

Халыкның мәшгульлек үзәге боерыгын әзерләү карар кабул ителгән

көнне гамәлгә ашырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече программа-техник комплекста боерык проектын формалаштыра. Әлеге боерык проекты имзалау өчен халыкның мәшгульлек үзәге директорына тапшырыла. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карар турында аның шәхси кабинеты аша белдерү җибәрә. Кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына белдерү җибәрү мөрәҗәгать итүчегә озата йөрү өчен җаваплы затның билгеләнүе турында хәбәр итү факты булып тора.

Боерык күчермәсе мөрәҗәгать итүченең шәхси эшенә теркәп куела.

3.4.3. Мөрәҗәгать итүчене озата йөрү өчен җаваплы затны билгеләү халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең мохтаҗ булуы турында карар кабул ителгән көннән соң икенче эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече программа-техника комплексында мөрәҗәгать итүчене озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәге белгече турында билге кертә һәм тәкъдимне мөрәҗәгать итүчегә аның шәхси кабинетына җибәрә.

3.4.5. Дәүләтнеке булмаган оешманы сайлау.

3.4.5.1. Дәүләтнеке булмаган оешманы сайлау халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарыла:

дәүләтнеке булмаган оешмада тиешле хезмәтне күрсәтү буенча Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хокукның булуын;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләтнеке булмаган оешма тарафыннан ярдәм күрсәтү тәртибе һәм шартларын;

оешмада инвалидларга ярдәм күрсәтү өчен әзерлекле персонал булуын.

Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләтнеке булмаган оешманы сайлап алуның максималь чоры – эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең озата йөрүгә мохтаҗ булуы турында карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне.

3.4.5.2. Халыкның мәшгульлек үзәге дәүләтнеке булмаган оешма белән инвалидны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтелгәндә озата йөрү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзи.

Шартнамә төзүнең максималь чоры – дәүләтнеке булмаган оешма сайланган көннән соң 10 эш көне.

3.4.5.3. Халыкның мәшгульлек хезмәте шартнамә төзелгән дәүләтнеке булмаган оешма турындагы белешмәләрне һәм шартнамә турындагы белешмәләрне шартнамә төзелгәннән соң бер эш көне эчендә Бердәм цифрлы платформага кертә.

Бердәм цифрлы платформада шартнамәләр төзелгән яисә үзләре белән шартнамәләр төзелергә мөмкин булган дәүләтнеке булмаган оешмалар реестры (алга таба – дәүләтнеке булмаган оешмалар реестры) формалаштырыла һәм алып барыла.

3.4.5.4. Дәүләтнеке булмаган оешма халыкның мәшгульлек үзәгенә Стандартның 3 нче кушымтасында китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк

буенча дәүләтнеке булмаган оешмалар реестрына кертү турында гариза бирергә хокуклы, түбәндәге ысулларның берсе белән:

а) кәгазь чыганакта шәхсән яисә, кушымталар исемлеге белән почта аша юллама рәвешендә, вәкил аша;

б) электрон почта ярдәмендә электрон файл формасында.

3.4.5.5. Халыкның мәшгульлек үзәге дәүләтнеке булмаган оешманы Регламентның 3.4.5.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны анализлау нигезендә дәүләтнеке булмаган оешмалар реестрына кертү турында карар кабул итә.

3.4.5.6. Халыкның мәшгульлек үзәге дәүләтнеке булмаган оешмаларга инвалидны эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру тәртибе, аларның әлеге озата йөрүдә катнашу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече инвалидны озата йөрү рәвешендә индивидуаль ярдәм күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешма турында программа-техник комплекска билге кертә һәм мөрәҗәгать итүчегә тәкъдимне мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрә.

3.4.6. Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып инвалидны эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәткәндә озата йөрү өчен җаваплы булган халыкның мәшгульлек үзәгенең җаваплы белгечен билгеләү яисә озата йөрүне гамәлгә ашырачак дәүләтнеке булмаган оешма белән шартнамә төзү тора.

Процедураның максималь вакыты – 15 эш көне.

3.5. Сертификат формалаштыру һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрү

3.5.1. Халыкның мәшгульлек үзәге Бердәм цифрлы платформадан файдаланып, мөрәҗәгать итүчене озата йөрү өчен җаваплы белгечне билгеләү турында боерык имзаланган яисә дәүләтнеке булмаган оешма белән шартнамә төзегән көннән соң киләсе эш көненнән соңга калмаган срокта сертификат формалаштыра.

Сертификат мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, формалаштырылган көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

3.5.2. Сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү чоры аны рәсмиләштергән көннән башлап алты ай тәшкил итә. Мөрәҗәгать итүче озата йөрү чоры беткәч дәүләт хезмәте күрсәтелү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформадан файдаланып, мөрәҗәгать итүчене озата йөрү чоры тәмамланган көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр җибәрә.

Эшкә урнаштыру турында эш бирүче белән сөйләшүләр алып барганда мөрәҗәгать итүчене озата йөрү сертификатта күрсәтелгән зат тарафыннан чаралар исемлеге нигезендә һәм сертификатта каралган срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып

формалаштырылган сертификатны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү тора.

Процедураның максималь вакыты – ике эш көне.

3.6. Сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү нәтиҗәләре турында Бердәм цифрлы платформага мәгълүмат кертү

3.6.1. Халыкның мәшгульлек үзәге сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү турындагы белешмәләрне мөрәҗәгать итүчене озата йөрү тәмамланган көннән соң киләсе биш эш көненнән дә соңга калмыйча, шул исәптән чоры бетүгә бәйле рәвештә дә, Бердәм цифрлы платформага кертә.

3.6.2. Мөрәҗәгать итүчене сертификат нигезендә дәүләтнеке булмаган оешма озата йөргән очракта, мөрәҗәгать итүчене озата йөрү турындагы белешмәләр Бердәм цифрлы платформага алар халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләтнеке булмаган оешмадан алынган көннән соң киләсе эш көненнән соңга калмыйча кертелә.

Дәүләтнеке булмаган оешма халыкның мәшгульлек үзәгенә сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү турындагы белешмәләрне мөрәҗәгать итүчене озата йөрү тәмамланган көннән соң киләсе биш эш көненнән дә соңга калмыйча, шул исәптән чоры бетүгә бәйле рәвештә дә, тапшыра.

3.6.3. Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып дәүләтнеке булмаган оешма тарафыннан сертификат нигезендә мөрәҗәгать итүчене озата йөрү нәтиҗәләре турында тулы мәгълүматны һәм тапшырылган белешмәләрне Бердәм цифрлы платформага кертү тора.

Процедураның максималь вакыты – алты эш көне.

3.7. Мөрәҗәгать итүчене эш урынында озата йөрү буенча тәкъдим ителгән чаралар исемлеген билгеләү, эш бирүче белән аның хакында фикер алышу

Халыкның мәшгульлек үзәге эшкә урнашу датасына кадәр бер көннән дә соңга калмыйча:

а) Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә мөрәҗәгать итүчене эш урынында озата йөргәндә киңәш ителә торган чараларны билгели (эш урынында мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча киңәш ителә торган чаралар исемлеге технологик картада билгеләнә);

б) эш бирүче белән элемтәгә керә һәм (эш бирүченең ризалыгы белән) мөрәҗәгать итүчене эш урынында озата йөргәндә киңәш ителә торган чаралар исемлеге, аларны үтәү сроклары турында фикер алыша.

Процедураның максималь вакыты – өч эш көне.

Административ процедураның (гамәлнең) нәтиҗәсе булып эш бирүче белән килешенгән мөрәҗәгать итүчене эш урынында озата йөрүнең чаралар исемлеге тора.

3.8. Индивидуаль планны формалаштыру инвалидка һәм эш бирүчегә җибәрү

3.8.1. Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүче белән эш урынында мөрәҗәгать итүчене озата йөрү буенча чаралар исемлеген килештергән көнне:

а) Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә индивидуаль планны, һәр чараны үткәрү вакытын формалаштыра;

б) Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль планны җибәрә;

в) индивидуаль планны эш бирүчегә җибәрә.

3.8.2. Мөрәҗәгать итүчене эш урынында озата йөрү эш бирүче тарафыннан башкарыла.

3.8.3. Халыкның мәшгульлек үзәге эш бирүчене технологик карта нигезендә эш бирүчегә һәм мөрәҗәгать итүчегә индивидуаль планны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат белән тәэмин итә.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә һәм эш бирүчегә индивидуаль планны җибәрү тора.

Процедураның максималь вакыты – бер эш көне.

3.9. Техник хаталарны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

3.9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән техник хаталарны төзәтү түбәндәге тәртиптә башкарыла:

мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм ялгышлар булуы ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә хаталарны һәм ялгышларны төзәтү зарурлыгы турында гариза белән мөрәҗәгать итә, гаризада Регламентның 5 нче кушымтасы нигезендә аларның тасвирламасы була, техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ теркәлә;

халыкның мәшгульлек үзәге, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән гариза алынган очракта:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларга тиешле үзгәрешләрне кертү зарурлыгы турындагы гаризаны карый; Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларда техник хаталарны бетерүне тәэмин итә;

гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Техник хаталарны бетерү срогы әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән гаризаны теркәү датасыннан соң бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

Сертификатны яисә индивидуаль планны яңадан рәсмиләштерү элегрәк бирелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларда җибәрелгән техник хаталарны бетерү сәбәпле, техник хаталары булган Сертификатны яисә индивидуаль планны теркәп, гариза алынган көнне халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан кабул ителгән һәм теркәлгән гариза нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гаризаны кабул итү турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә гариза кабул ителгән көнне Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә җибәрелә.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формасы

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүне агымдагы тикшереп тору (алга таба – агымдагы тикшереп тору):

2) туры килә торган эшне эзләгәндә һәм халыкның мәшгульлек хезмәте органнары тарафыннан эшкә урнаштырганда мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән инвалидларга түләүсез ярдәм күрсәтү өлешендә халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тоту (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тоту).

4.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгечләренең әлеге Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеле торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвенә агымдагы контроль халыкның мәшгульлек үзәге директоры яки ул вәкаләт биргән белгеч тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлек халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н санлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларына белешмәләрне бирү тәртибен, чорларын һәм рәвешен, шулай ук аларда булган мәгълүмат төрләре исемлеген дә кертеп, Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрын алып бару тәртибен, эш бирүчеләрнең исәпкә алу документлары һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген билгели торган башка документларны кәгазьләрен тутыру, алып бару һәм саклауга карата таләпләрне саклау һәм үтәү буенча тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыру өчен әлеге Регламентны үтәү күрсәткечләре, күрсәткечләрне исәпләп чыгару өчен кирәкле булган белешмәләр һәм аларны тапшыру тәртибе, Стандартның 4 нче кушымтасына ярашлы рәвештә күрсәткечләрне бәяләү (хисаплау) методикасы кулланыла;

4.4. Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тотуны, эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлешендәге дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүенә күзәтчелек һәм контроль буенча вәкаләтләрне үтәү кысаларында Министрлык гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан планлы (планнан тыш) урынга чыгып (документар) тикшерүләр уздыру юлы

белән гамәлгә ашырыла.

4.5. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Тикшерүләр уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеге, планлы урынга чыгып (документар) тикшерүләрне уздыру ешлыгы Министрлык тарафыннан билгеләнә.

4.7. Планлы (планнан тыш) урынга чыгып (документар) тикшерүләрнең нәтиҗәләре бозуларның сәбәпләрен ачыклау һәм аларны бетерү һәм булдырмау буенча чаралар күрү максатларында анализланырга тиеш.

4.7.1. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – КФҮ гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $15^1$ статьясында күрсәтелгән гаризаны теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты бозылганда;

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматлар тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тарту;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге, дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге белгече, КФҮ, КФҮ хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда Мөрәҗәгать итүчедән, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи зат (белгеч) яки дәүләт хезмәткәре, КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Шикаять почтадан, КФҮ аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), КФҮ рәсми

сайтыннан (http://mfc16.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru/), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гражданинны шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең (http://mfc16.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда

җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы гражданинга язмача яисә, гражданин ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение), КФҮ, КФҮ хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гражданинга эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына
1 нче кушымта

Киңәш ителә торган үрнәк
Стандартка 1 нче кушымтада китерелгән

Инвалидка эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә озата йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) ____________________________
________________________________________________________________________________
2. Җенесе ______________________________________________
3. Туган көне, ае, елы ________________________________________________________
4. Гражданлыгы ________________________________________________________
5. ИНН ______________________________________________________________
6. СНИЛС __________________________________________________________
7. Шәхесне раслаучы документ төре _____________________________
8. Шәхесне раслаучы документның сериясе, номеры _____________________
9. Шәхесне раслаучы документны бирү датасы ______________________

10. Шәхесне раслаучы документ кем тарафыннан бирелгән ______________________
___________________________________________________________________

11. Адресы:

а) яшәү урыннары (даими теркәлү):

- Россия Федерациясе субъекты ______________________________________

- район, торак пункт, урам ____________________________________
___________________________________________________________________

- йорт, корпус, төзелмә, фатир ______________________________________
___________________________________________________________________

12. Элемтә ысулы:

а) телефон _________________________________________________________

б) электрон почта адресы (булган очракта) ____________________________

13. Хезмәт күрсәтү урыны:

а) Россия Федерациясе субъекты _______________________________________

б) халыкның мәшгульлек үзәге _______________________________________

Мәгълүматларны раслау:

☐ Әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белдерәм, шул исәптән түбәндәгеләр өчен дә:

- әлеге мөрәҗәгатьне дәүләт органына, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләренә яисә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү аның компетенциясенә карый торган вазыйфаи затка җибәрү;

- әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатыннан өченче затларга шәхси мәгълүматларымны тапшыру.

☐ МСЭ учреждениесеннән эш белән тәэмин иткәндә булышлык күрсәткәндә инвалидның озата йөрүгә мохтаҗ булмавы турында белешмәләр (киңәшләр) алынган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылырга мөмкин булуы турында миңа кисәтелде.

☐ Тормыш эшчәнлегендә булган чикләмәләр, киңәш ителгән яисә киңәш ителми торган хезмәт эшчәнлеге төрләре турында, ИПРА күрсәтелгән киңәш ителә торган хезмәт шартлары турында белешмәләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылырга мөмкин булуы турында миңа кисәтелде.»;

5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«__________________ халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе

_________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: ____________________________________________
____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
____________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)
____________________________________________________________________

техник хатаны төзәтүне сорыйм __________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________,
халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан 20___ елның ___________ бирелгән № _____________ җибәрелгән.
Үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны алуга риза
_________________________________________________________________
(шәхсән, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткәндә яки почта аша язмача, электрон почта аша, мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына)
____________________________________________________________________

«__» _________ 20__ ел. __________________ _________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)»;

түбәндәге эчтәлекле кушымта (белешмәлек) өстәргә:

«Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Инвалидларны эшкә урнаштырганда булышлык күрсәтүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| Халыкның мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|---|
| «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-90 | Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-73-94 | Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85552) 3-09-83 | Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84346) 2-15-89 | Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-34-99 | Czn.Almet@tatar.ru |
| «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | Czn.Apastovo@tatar.ru |
| «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-17-33 | Centr.Arskiy@tatar.ru |
| «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-51 | Czn.Atnya@tatar.ru |
| «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-62-29 | Czn.Bavly@tatar.ru |
| «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-44-19 | Czn.Baltasi@tatar.ru |
| «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-17-60 | Czn.Bugulma@tatar.ru |
| «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-13-73 | Czn.Buinsk@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84379) 2-18-99 | Czn.V-uslon@tatar.ru |
| «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 3-16-17 | CZN.VGora@tatar.ru |
| «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84375) 2-25-87 | Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557) 7-58-58 | Czn.Elabugi@tatar.ru |
| «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558) 7-15-43 | Czn.Zainsk@tatar.ru |
| «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371) 5-64-90 | Czn.Zdol@tatar.ru |
| «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370) 2-12-60 | Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364) 2-67-54 | Czn.Kukmor@tatar.ru |
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84378) 2-48-12 | Laish.Czn@tatar.ru |
| «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595) 5-59-70 | Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85563) 3-35-57 | Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерже районы филиалы | директор | (85549) 2-23-57, (85551) 2-31-73 | Czn.Men@tatar.ru Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85555) 3-23-80 | Czn.Menzelinsk@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-55-80 | Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | директор | (8552) 52-42-68 (8552) 52-96-97 | Chelny.CZN@tatar.ru Czn.Tukaev@tatar.ru |
| «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 (8555) 33-98-61 | Czn.Nk@tatar.ru Czn.Nk@tatar.ru |
| «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84348) 2-30-42 | Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-30 | Czn.Nurlat@tatar.ru |
| «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84362) 2-28-15 | SZN.Saby@tatar.ru |
| «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | Czn.Bolgar@tatar.ru |
| «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт | директор | (84373) 2-63-29, (84377) 2-14-67 | Czn.Tetyushi@tatar.ru Filial.K-uste@tatar.ru |

| | | | |
|---|---|---|---|
| казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | | | |
| «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-13-51 | Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-13-34 | Czn.chist@tatar.ru |
| «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85593) 2-98-00 | Czn.Yutazy@tatar.ru |
| «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | директор | (843) 562-48-33 (843) 273-85-03 | Czn.g_Kazan@tatar.ru CZN.Sovetskiy@tatar.ru |
| «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 537-86-00 | Czn.Avia@tatar.ru |
| «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 277-40-09 | Czn.Vah@tatar.ru |
| «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 554-77-36 | czn.kirovskiy@tatar.ru |
| «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 564-58-72 | czn.moskovski@tatar.ru |
| «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 560-88-98 | Czn.Novosavin@tatar.ru |
| «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 224-86-83 | CZN.Privol@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru». |